МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.06.2022 Казан ш. № 627

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 27 июнендәге 627 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.3. Хезмәт базарында килеп туган хәлне исәпкә алып, туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчеләргә нәтиҗәле ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре тарафыннан туры килә торган эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарны профильләштерү (әлеге гражданнарны, аларның алдагы һөнәри эшчәнлеге өлкәсенә, җенесенә, яшенә һәм башка социаль-демографик характеристикаларына, шулай ук хезмәт базарындагы статусына, эшкә урнашу потенциалына һәм эшкә урнашуга мотивацияләүгә бәйле рәвештә, төркемнәргә бүлү) буенча махсус чаралар оештыру һәм уздыру гамәлгә ашырыла (әлеге функцияне гамәлгә ашырганнан соң)»;

1.3.1 – 1.5 пунктларны көчен югалткан дип танырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт оешмалары (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге) тарафыннан күрсәтелә. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба - КФҮ) һәм (яки) КФҮнең ерактагы эш урыны аша бирергә мөмкин.

КФҮ белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителми.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

туры килә торган эш тәкъдим итү;

сөйләшүләр алып барылуы турында хәбәр итү яисә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле документларның рәвешләрен раслау турында» 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыгы (алга таба - 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык) белән расланган үрнәк буенча эшкә юллау;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим;

өч яше тулганчы, бала карау буенча ял иткән чорда хатын-кызларга халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем алырга тәкъдим итү;

картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңартып җибәрергә омтыла торган, шөгыле булмаган гражданнарга эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне узарга тәкъдим итү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар – физик затлар регистрында теркәлә (алга таба – Физик затлар регистры).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

«Работа в России» (https://www.trudvsem.ru/) эш белән тәмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформасыннан (алга таба – «Работа в России» порталы), шул исәптән Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) , Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://www.uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 2 ноябрендәге 1909 номерлы карары белән расланган Туры килә торган эш эзләү максатларында гражданнарны теркәү кагыйдәләре (алга таба – Гражданнарны теркәү кагыйдәләре) нигезендә электрон документ рәвешендә;

мөрәҗәгать итүчегә шәхсән кәгазь чыганакта.

### 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Туры килә торган эш эзләү максатларында мөрәҗәгать итүчене теркәгән көннән башлап киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, шул исәптән

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) КФҮ һәм (яки) КФҮ ерактагы эш урыны, Бердәм портал, «Работа в России» порталы, Татарстан Республикасы порталы аша килгәндә дә, буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында «Работа в России» порталында булган белешмәләрдән чыгып, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш сайлап алуны гамәлгә ашыра.

2.4.2. «Работа в России» порталында эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүматлар булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә «Работа в России» порталына эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләр кергән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча туры килә торган эш сайлый.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүче эшкә урнашмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге туры килә торган эш буенча сайлап алынган ике вариант буенча сөйләшүләр уздыру көне һәм аның нәтиҗәләре турында «Работа в России» порталына мәгълүмат алынган яисә, эшкә алучы «Работа в России» порталында теркәлмәгән очракта, мөрәҗәгать итүче эшкә алучының мөрәҗәгать итүченең килгән көне һәм эшкә алудан баш тарту сәбәбе турындагы тамгасы белән юллама тапшырылган көннән соң бер эш көне узганчы туры килә торган эш сайлап алуны яңадан гамәлгә ашыра.

2.4.4. Мөрәҗәгать итүченең туры килә торган эш вариантларын сайлап алу һәм килештерү өчен, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш сайлап алу мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.5. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче белән туры килә торган эш вариантларын килештерү максатларында, мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул иткән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә «Работа в России» порталыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүче өчен эшкә юллау турында мәгълүмат булган белдерүне җибәрә.

2.4.6. Мөрәҗәгать итүче кандидатурасын эш бирүчеләр белән килештерү вакыты мөрәҗәгать итүчедән туры килә торган эш (вакансияләр) тәкъдимнәренең төзелгән исемлеген алган көннән алып бер эш көненнән дә артмый.

2.4.7. Халыкның мәшгульлек үзәге, эш бирүче белән килештерү нәтиҗәләре нигезендә, мөрәҗәгать итүчегә «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүчедән туры килә торган эш (вакансияләр) тәкъдимнәренең төзелгән исемлеген алган көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр уздырылуы турында белдерү җибәрә.

2.4.8. Эш бирүче «Работа в России» порталында теркәлмәгән булса, халыкның мәшгульлек үзәге 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык белән расланган форма буенча эшкә юллама рәсмиләштерә. Мөрәҗәгать итүчегә сөйләшүләр уздыруга юлламаны рәсмиләштерү турында белдерү мөрәҗәгать итүчегә әлеге юллама белән бергә, аннан туры килә торган эш (вакансияләр) тәкъдимнәренең төзелгән исемлеген алган көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган:
дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;
дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) турында белешмәләр;
дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала:
«Работа в России» порталын, Бердәм порталны, Татарстан Республикасы порталын кулланып, 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык белән расланган формалар буенча Гражданнарны теркәү кагыйдәләре нигезендә электрон документ формасында җибәрелгән гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасы һәм резюмесы (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);
халыкның мәшгульлек үзәгендә туры килә торган эш эзләү максатларында гражданинны теркәгәндә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән документлар һәм (яки) алынган белешмәләр нигезендә Физик затлар регистрына кертелгән гражданин турында белешмәләр.
Гаризаны Бердәм порталны яисә Татарстан Республикасы порталын кулланып юллаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче «Работа в России» порталын кулланып, гариза юлланган көннән алып өч календарь көннән дә соңга калмыйча резюме җибәрә. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә резюмены гариза җибәрелгән көннән алып өч календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрергә кирәклеге турында белдерү юллый.
Электрон рәвештәге гариза һәм резюме халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану турында» 2013 елның 25 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану кагыйдәләре нигезендә алынган гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле булмаган, тикшерү сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик

бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган имза белән имзалана.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

«Работа в России» порталындагы шәхси кабинет аша;

Бердәм портал аша;

Татарстан Республикасы порталы аша;

күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша;

халыкның мәшгульлек үзәгенә «Работа в России» порталына керүне тәэмин итеп, шәхсән килгән очракта.

Мөрәҗәгать итүче үз ихтыяры белән шәхсән килеп халыкның мәшгульлек үзәгенә яисә күпфункцияле үзәккә электрон рәвештә гариза һәм резюме тапшыруда ярдәм сорап яки халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме буенча туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчеләргә «Работа в России» порталына, Бердәм порталга һәм Татарстан Республикасы порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән затта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм атутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуы булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге яки күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче зат риза булган очракта, әлеге системада мөрәҗәгать итүченең процедуралар узып бетерүен тәэмин итә.

2.6.2. Туры килә торган эш эзләү максатларында теркәлгән мөрәҗәгать итүче (алга таба – теркәлгән мөрәҗәгать итүче) 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документларны шәхсән тапшыра, шул исәптән:

чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

белем һәм (яки) квалификация турында хәрби һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче хәрби мәгариф оешмалары тарафыннан бирелә торган, шулай ук 1992-1995 елларда Россия Федерациясе территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашырган оешмалар тарафыннан бирелгән документлар;

белем алу һәм (яки) квалификация турында һәм белем алуга бәйле, чит ил дәүләте территориясендә бирелгән документлар һәм аларның нотариаль яктан таныкланган рус теленә тәрҗемәсе.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Соңгы эш урыны (хезмәт) буенча уртача эш хакын исәпләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 14 сентябрендәге 1552 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 14 сентябрендәге 1552 номерлы карары) белән расланган Соңгы эш урыны (хезмәт) буенча уртача эш хакын исәпләү кагыйдәләренең 3 пунктында каралган очракларда, теркәлгән мөрәҗәгать итүче соңгы эш (хезмәт) урыны буенча уртача хезмәт хакы турында белешмә тапшыра.

2.6.3. Теркәлгән мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне раслый торган документларны шәхсән тапшыра ала:

а) аның «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы закон) 5 статьясында каралган эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнар категориясенә кертелүен, шулай ук түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала торган:

иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче оешмалардан чыгарылуы турында;

качаклар яки мәҗбүри күченүчеләр категориясенә кертелүе турында;

хәрби хезмәттән куылуы турында яки хәрби хезмәттән куылган гражданин белән туган булуы турында;

балигълык яшенә җитмәгән балаларны, инвалид балаларны тәрбияләүче ялгыз һәм күп балалы ата-аналар категориясенә кертелүе турында;

Чернобыль һәм башка радиация һәлакәтләре һәм катастрофалар аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнар категориясенә кертелүе турында;

б) теркәлгән мөрәҗәгать итүченең гыйльми дәрәҗәсе һәм исемнәре турында белешмәләр.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр һәм аннан соң килгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче поспортын яисә аны алмаштыра торган документны күрсәтә.

2.6.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

паспортның хакыйкыйлыгы турында мәгълүмат – Россия Эчке эшләр министрлыгы (ведомство мәгълүмат системасы);

яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр – Россия ЭЭМ (ведомство мәгълүмат системасы);

хезмәт эшчәнлеге, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру факты турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

хезмәт стажы турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

мәҗбүри пенсия иминияте өчен иминият кертемнәре түләнгән соңгы эш (хезмәт) урыны буенча түләүләр һәм башка төрле бүләкләүләр турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

инвалидлык турында белешмәләр (инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан өземтә (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия Федерациясе Пенсия фонды («Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

белеме, квалификациясе турында белешмәләр – Рособрнадзор («Белем турында һәм (яки) квалификация, белем алу турында документлар турында мәгълүматларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

лаеклы ял алды яшендәге гражданнарга кертелү турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (Социаль тәэмин итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасы);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар – Россия ФСХ (Юридик затларның бердәм дәүләт реестры);

Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр – Россия ФСХ (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры);

юридик затларны гамәлгә куючылар (катнашучылар) булган гражданнар турында белешмәләр – Россия ФСХ (Юридик затларның бердәм дәүләт реестры);

һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусы турында мәгълүмат – Россия ФСХ («Һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусын тикшерү» гавами сервисы;

адвокат статусы турында белешмәләр – Россия Юстиция министрлыгы (Россия Федерациясе субъектларының адвокатлар реестры);

нотариус вәкаләтләре һәм квалификация имтиханын тапшырган затлар турында белешмәләр – Россия Юстиция министрлыгы (нотариуслар һәм квалификация имтиханын тапшырган затлар реестры);

бала туу турында белешмәләр (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия ФСХ (Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестры);

гражданинның үлеме турында белешмәләр – Россия ФСХ (Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестры);

пенсия алу факты турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

гражданнарны ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар категориясенә кертү турында мәгълүмат (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия Федерациясе Пенсия фонды (Социаль тәэмин итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасы).

2.6.6. Ведомствоара гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон

хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында җибәрелә.

2.6.7. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.8. Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул итүдән баш тарту өчен нигез түбәндәгеләр булып тора:

халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүченең резюмены гариза җибәрелгәннән соң өч календарь көн узганчы халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрмәве;

резюменың мәгълүматка карата таләпләргә туры килмәве;

мөрәҗәгать итүченең, аның резюмесы «Работа в России» порталында урнаштырылган мәгълүматка карата таләпләргә туры килүе шарты белән, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаның һәм резюменың аның яшәү урынына карамаган мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең билгеләнгән чорда халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәве.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып гражданинның мәшгульлек үзәге тарафыннан һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем алуга җибәрелүе тора.

2.8.2. Мөрәҗәгать итүче туры килә торган эшне сайлау һәм килештерү өчен шәхсән килгән очракта, аңа халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләре күрсәтүдән баш тарту, шул исәптән аңа әңгәмә узу өчен эшкә алучыга юллама бирү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Гражданнарны теркәү кагыйдәләре нигезендә җибәрелгән, электрон документ формасындагы гаризаның һәм резюменың тапшырылмавы;

ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, ведомствоара гариза җибәрү нәтиҗәсендә Россия ЭЭМ паспортның хакыйкый булмавы турында белешмәләр алынуы.

2.8.3. Алга таба мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракларда, паспорт яки аны алмаштыручы документның булмавы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.8.4. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.8.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү, мөрәҗәгать итүчене туры килә торган эш эзләү максатларында теркәү исәбеннән төшергән очракта, түбәндәге очракларда туктатыла:

а) теркәлгән мөрәҗәгать итүченең эшкә урнашуы;

б) теркәлгән мөрәҗәгать итүченең, «Работа в России» порталын кулланып, шул исәптән Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша электрон формада халыкның мәшгульлек үзәге белән озак вакыт дәвамында (теркәлгән мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәге белән үзара хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра башларга тиеш булган, халыкның мәшгульлек үзәге белдерүендә күрсәтелгән датадан башлап бер айдан артык вакыт дәвамында) үзара хезмәттәшлек итмәве;

в) теркәлгән мөрәҗәгать итүченең төзәтү яки мәҗбүри эшләргә хөкем ителүе, шулай ук, әгәр мондый җәза шартлы рәвештә билгеләнмәгән булса, иректән мәхрүм итү рәвешендә җәзага тартылуы;

г) «Работа в России» порталын яки Бердәм порталны (гариза Бердәм портал аша җибәрелгән очракта) кулланып һәм Татарстан Республикасы порталын кулланып (гариза Татарстан Республикасы порталы аша җибәрелгән очракта), теркәлгән мөрәҗәгать итүче гаризасын кире алган очракларда, теркәлгән мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белән хезмәттәшлек итүдән баш тартуы. Теркәлгән мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаны кире кайтартып алу, үзен эшсез дип тану өлешендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризага үзгәрешләр кертелгән очракта, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризага һәм резюмега гариза халыкның мәшгульлек үзәгендә кабул ителгән көнгә кадәр үзгәрешләр кертелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белән хезмәттәшлек итүдән баш тарту булып тормый;

д) теркәлгән гражданин тарафыннан Гражданнарны теркәү кагыйдәләренең 6 пункты нигезендә гаризаны кире кайтартып алу;

е) теркәлгән гражданинның вафат булуы.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза «Работа в России» порталын кулланып, чират тәртибендә бирелә. Чиратта тору вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.10.2. Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә «Работа в России» порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны көтү вакыты биш минуттан артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате кирәкле барлык документлары белән гариза һәм резюме алынган көнне теркәлә.

Гариза һәм резюме мөрәҗәгать итүче тарафыннан үзенең яшәү урыны буенча карамаган халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән очракта, резюме мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көнне мәгълүматка карата таләпләргә туры килү шарты белән, гариза халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан кабул ителә (теркәлә). Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килү кирәклеге турында белдерү резюмены бәяләү процедурасы тәмамланганнан соң, мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.11.2. Гариза һәм резюме халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче тарафыннан ял көне яки эшләми торган бәйрәм көнендә җибәрелгән очракта, гариза җибәрү көне дип аның артыннан киләсе эш көне санала.

2.11.3. Күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең еракатагы эш урынына шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәктән, күпфункцияле үзәкнең еракатагы эш урыныннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән гариза тапшырылган көнне язу бирелә.

2.11.4. Гариза «Работа в России» порталы, Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүче «Работа в России» порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның кабул ителүен раслый торган белдерү ала, анда гаризаны теркәү номеры һәм датасы күрсәтелә.

## 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) дәүләт хезмәтен күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм чорлары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында мөрәҗәгать итүче өчен индивидуаль яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү мөмкинлеге (шәхси кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмати материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү юлы белән, «Работа в России» порталында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында мәгълүмат урнаштыру юлы белән);

мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларның һәм башка документларның үрнәкләрен алуны, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән дә, тәэмин итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта аша, «Работа в России» порталы, Бердәм портал һәм Татарстан Республикасы порталы, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге;

күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү чорларының үтәлүе;

әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге саклану;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы;

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 20 минуттан артмый.

2.13.4. Дәүләт хезмәте (консультацияләү һәм гариза һәм резюмены кабул итүдән тыш) күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында күрсәтелми.

Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарына мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм резюме теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе халыкның мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары белән төзелә торган үзара хезмәттәшлек турындагы килешү белән җайга салына, ә күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарының мөрәҗәгать итүчеләр белән – күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарының эш регламенты белән.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Работа в России» порталындагы шәхси кабинеты аша, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында, КФҮ, КФҮнең ерактагы урынында алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, хезмәт күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрне карау «Работа в России» порталындагы шәхси кабинетында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында мөрәҗәгать итүчене алдан авторизацияләмичә башкарыла.

«Работа в России» порталындагы шәхси кабинетта, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында авторизация узганнан соң мөрәҗәгать итүче түбәндәге мөмкинлекләргә ия була: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны тапшыру, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында белешмәләр алу, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу.

## 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүдән тыш, теркәлгән гражданнарга туры килә торган эш вариантлары исемлеген җибәрүдән тыш, электрон рәвештә күрсәтелми.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) «Работа в России» порталында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) «Работа в России» порталын, Бердәм порталны, Татарстан Республикасы порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирергә;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) «Работа в России» порталы, Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон белдерү формасында алырга;

е) дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган «Работа в России» порталы, Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә ПОО, Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гариза, туры килә торган эш вариантлары исемлеге Татарстан Республикасы Порталы, Бердәм портал, «Работа в России» порталы аша җибәрелә ала.

2.14.4. Гаризаны төзү, гаризаны һәм резюмены өстәмә рәвештә нинди дә булса башка рәвештә тапшыру зарурлыгыннан тыш, «Работа в России» порталында яки Бердәм порталда гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Гаризаны Бердәм порталны яисә Татарстан Республикасы порталын кулланып юллаган очракта, мөрәҗәгать итүче «Работа в России» порталын кулланып, гариза юлланган көннән алып 3 календарь көннән дә соңга калмыйча резюме җибәрә.

2.14.5. Яңадан теркәлү даталары арасында, «Работа в России» порталына буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүмат кергән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча, халыкның мәшгульлек үзәкләре

мөрәҗәгать итүчеләргә, «Работа в России» порталыннан файдаланып, туры килә торган эш (вакансия) вариантлары исемлеген җибәрәләр.

2.14.6. Мөрәҗәгать итүчеләрне халыкның мәшгульлек үзәгенә кабул итү өчен язу (алга таба – кабул итү өчен язу) Татарстан Республикасы порталы, халыкның мәшгульлек үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгендә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы порталы яки халыкның мәшгульлек үзәге телефоны аша алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Работа в России» порталы;

Физик затлар регистры

2.14.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.»;

3 бүлектә:

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары»;

3.3.4.4 пунктта:

өченче абзацта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Соңгы эш (хезмәт) урыны буенча уртача хезмәт хакын исәпләп чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 14 сентябрендәге 1552 номерлы карары белән расланган тәртиптә исәпләнгән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның

14 сентябрендәге 1552 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр нигезендә исәпләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «әлеге Регламентның 2.5 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.6пункты» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән затларга дәүләт хезмәте күрсәтү

3.5.1. Беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән затларга дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

1) мөрәҗәгать итүче турында «Работа в России» порталындагы мәгълүматларны анализлау;

2) мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш сайлау;

3) туры килә торган эш вариантларын мөрәҗәгать итүче белән килештерү;

4) эш бирүче белән мөрәҗәгать итүче кандидатурасын килештерү;

5) эшкә алучы белән сөйләшүләр уздырылуы турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү җибәрү һәм, эшкә алучы «Работа в России» порталында теркәлмәгән булса, туры килә торган эшнең ике варианты буенча мөрәҗәгать итүчегә эшкә юлламалар бирү;

6) эшсез дип танылуга дәгъва белдерүче мөрәҗәгать итүчегә, эшсез мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгеннән эшкә алучы белән сөйләшүләр уздырылуы турында белдерү яки, эшкә алучы «Работа в России» порталында теркәлмәгән булса, эшкә юллама алынган көннән башлап өч эш көне эчендә «Работа в России» порталын, шул исәптән Бердәм порталны, Татарстан Республикасы порталын кулланып, электрон формада халыкның мәшгульлек үзәгенә туры килә торган эшнең ике варианты буенча эшкә алучы белән сөйләшүләр уздыру көне һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат тапшыру яки мөрәҗәгать итүченең килү көне һәм эшкә алудан баш тарту сәбәбе турында эшкә алучы тамгасы белән юллама тапшыру зарурлыгы турында хәбәр итү;

7) эшсез дип танылуга дәгъва итүче мөрәҗәгать итүченең туры килә торган эш вариантыннан баш тартуын рәсмиләштерү;

8) мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш вариантлары булмаган очракта, түбәндәгеләрне тәкъдим итү:

эш эзләү критерийларын төгәлләштерү максатында резюмега төзәтмәләр кертү (кирәк булганда), шул исәптән «Мое резюме» сервисын гамәлгә ашыру кысаларында да;

чиктәш һөнәр буенча эш (белгечлек);

хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар таләпләренә җавап бирә торган, алдан әзерләнүне таләп итә яки таләп итми торган вакытлыча характердагы эшне дә кертеп, эш бирүчеләргә мөстәкыйль бару өчен түләнә торган эш вариантлары;

эш урынына транспорт белән бару мөмкинлеген исәпкә алмаган, ләкин Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законда каралган башка критерийларга туры килә торган эш, бер үк вакытта эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка урынга күченгәндә эшсез

гражданнарга һәм күченеп урнашканда эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тәкъдим итеп;

билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне;

башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне;

халыкны эш белән тәэмин итү турында законның 7.1-1 статьясында билгеләнгән халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләре күрсәтүне.

9) өч яшенә җиткәнче бала карау буенча отпускта булган хатын-кызларга, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген дәвам итәргә омтылган гражданнарга эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча профессиональ укырга яки өстәмә һөнәри белем алырга тәкъдим итү;

10) административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен Физик затлар регистрына кертү.

3.5.2. Мөрәҗәгать итүче турында «Работа в России» порталындагы мәгълүматларны анализлау

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче турында «Работа в России» порталындагы белешмәләргә, шулай ук әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында каралган ведомствоара гаризаларны юллау юлы белән алынган белешмәләргә анализ уздыра һәм түбәндәгеләр турында белешмәләр булуын яки булмавын исәпкә алып, халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар нигезендә аңа туры килә торган эшне билгели:

һөнәрләре (белгечлекләре), вазыйфалары, эшчәнлек төрләре турында белешмә;

һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсе, эш тәҗрибәсе һәм күнекмәләре турында белешмә;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 14 сентябрендәге 1552 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр нигезендә исәпләнгән соңгы эш (хезмәт) урыны буенча уртача хезмәт хакы турында;

яшәешендә чикләмәләре булган гражданнар өчен индивидуаль тернәкләндерү яки абилитация программасында булган киңәш ителә торган хезмәт рәвеше һәм шартлары турында.

Кирәк булганда, мөрәҗәгать итүче турындагы мәгълүматларны анализлау нәтиҗәләре буенча, халыкның мәшгульлек үзәге шул ук көнне, туры килә торган эш критерийларын төгәлләштерү максатыннан, резюмега төзәтмә кертү

тәкъдиме белән, шул исәптән «Мое резюме» сервисын гамәлгә ашыру кысаларында да, аңа белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчене туры килә торган эш эзләү максатларында теркәү исәбенә куйган көнне гамәлгә ашырыла, алга таба – мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган яисә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан туры килә торган эш эзләү максатларында мөрәҗәгать итүчене теркәгәндә, мөрәҗәгать итүчене эшсез дип тану турында карар кабул иткәндә, яңадан рәсмиләштергәндә һәм халыкның мәшгульлек үзәге ихтыяры буенча башка очракларда ведомствоара электрон хезмәттәшлек итүнең бердәм системасыннан файдаланып алынган документларны һәм (яки) үзе турында белешмәләрне алган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче турындагы мәгълүматларны анализлау.

3.5.3. Мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш сайлау

Туры килә торган эш (вакансияләр) тәкъдимнәре исемлеге, «Работа в России» порталындагы буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турындагы белешмәләрдән чыгып, «Работа в России» порталындагы вакансияләрне интеллектуаль эзләү технологиясен кулланып, автоматлаштырылган режимда төзелә.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эшне туры килә торган эш эзләү максатында мөрәҗәгать итүчене теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча сайлап ала, түбәндәгечә:

автомат рәвештә формалаштырылган туры килә торган эш (вакансияләр) тәкъдимнәре исемлеген анализлау һәм мөрәҗәгать итүчегә аеруча туры килә торган вариантларны сайлап алу юлы белән;

«Работа в России» порталын кулланып, туры килә торган эш вариантларын өстәмә эзләү юлы белән (кирәк булганда).

«Работа в России» порталында эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүматлар булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә «Работа в России» порталына эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләр кергән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча туры килә торган эш сайлый.

Мөрәҗәгать итүче эшкә урнашмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге туры килә торган эш буенча сайлап алынган ике вариант буенча сөйләшүләр уздыру көне һәм аның нәтиҗәләре турында «Работа в России» порталына мәгълүмат алынган яисә, эшкә алучы «Работа в России» порталында теркәлмәгән очракта, мөрәҗәгать итүче эшкә алучының мөрәҗәгать итүченең килгән көне һәм эшкә алудан баш тарту сәбәбе турындагы тамгасы белән юллама тапшырылган көннән соң бер эш көне узганчы туры килә торган эш сайлап алуны яңадан гамәлгә ашыра.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш вариантларын сайлап алу һәм килештерү, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүче теркәлгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча мәшгульлек үзәгенә

бару датасын билгеләргә хокуклы. Халыкның мәшгульлек үзәгенә килү датасын күрсәтелгән белдерү мөрәҗәгать итүчегә аны туры килә торган эш эзләү максатларында теркәгән көнне «Работа в России» порталы аша гаризада күрсәтелгән гражданинның электрон почтасына текст хәбәрен автоматлаштырып формалаштыру һәм тапшыру юлы белән җибәрелә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә, «Работа в России» порталында булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләрдән чыгып, һөнәр (белгечлек), вазыйфа, эшчәнлек төре, һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсе, эш тәҗрибәсе һәм күнекмәләре, соңгы эш урыны буенча уртача хезмәт хакы күләме, хезмәт шартлары һәм һәркем файдалана алырлык эш урыннары турында тәкъдимнәр, эш урынының транспорт белән файдалана алырлык булуы, мөрәҗәгать итүченең үз эшенә теләкләре, шулай ук кандидатның хезмәт функциясен үтәүгә карата эш бирүче таләпләреннән чыгып, туры килә торган эш вариантларын сайлап ала.

Эш бирүчедән алар өчен туры килә торган, телдән (телефоннан) яисә язма (электрон документ рәвешендә) рәвештә туры килә торган буш эш урыны һәм вакантлы вазыйфа булуы турында белешмәләр кергән очракта, алар турында белешмәләрне Физик затлар регистрында булган мөрәҗәгать итүчеләргә халыкның мәшгульлек үзәгенә өч көн эчендә эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү өчен килергә тәкъдим ителә.

Туры килә торган эшне сайлаганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

бер үк төрле эш вариантын ике тапкыр тәкъдим итү, ә беренче тапкыр эш эзләүче, элек бер дә эшләмәгән һәм әле һөнәре (белгечлеге) дә булмаган гражданнарга һөнәри әзерлекнең бер үк вариантын ике тапкыр тәкъдим итү:

эш урынына транспорт белән бару мөмкинлеген тәэмин итә торган җәмәгать транспорты челтәре үсешен исәпкә алмыйча, эш урыннарына юллау;

мөрәҗәгать итүчеләр ризалыгыннан башка яшәү урынын үзгәртүгә бәйле эш тәкъдим итү;

хезмәт шартлары хезмәт сагы кагыйдәләре һәм нормаларына туры килми торган эш тәкъдим итү;

эш хакы мөрәҗәгать итүченең соңгы эш урыны буенча соңгы өч айда исәпләнгән уртача хезмәт хакыннан түбәнрәк булган эш тәкъдим итү. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләп чыгарылган уртача айлык хезмәт хакы эшкә яраклы халыкның яшәү минимумы күләменнән артып киткән мөрәҗәгать итүчеләргә кагылмый.

«Работа в России» порталында туры килә торган эш вариантлары булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне бастырып чыгара һәм аны мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне алу.

3.5.4. Мөрәҗәгать итүче белән туры килә торган эш вариантларын килештерү.

Халыкның мәшгульлек үзәге, мөрәҗәгать итүче белән туры килә торган эш вариантларын килештерү максатларында, мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул иткән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә «Работа в России» порталыннан файдаланып түбәндәгеләрне җибәрә:

а) туры килә торган эш (вакансияләр) тәкъдимнәре исемлеген, анда 10 тәкъдимнән артык булмаган эш (вакансия) була;

б) мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган белдерү:

туры килә торган эшнең кимендә ике өстенлекле вариантын сайлап алып, вакансияләрне өстенлекле тәртиптә билгеләү кирәклеге турында;

эшсез дип танылуны дәгъвалаучы мөрәҗәгать итүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә «Работа в России» порталын кулланып, шул исәптән Бердәм порталны яки Татарстан Республикасы порталын кулланып, туры килә торган эшнең ике вариантын сайлау турындагы мәгълүматны да үз эченә алган, тәкъдим ителгән эшләр (вакансияләр) исемлеген тәкъдим ителгән эшләр (вакансияләр) исемлеген алган көннән алып ике календарь көн эчендә җибәрү кирәклеге турында;

эшсез мөрәҗәгать итүче тарафыннан, «Работа в России» порталын кулланып, шул исәптән Бердәм портал яки Татарстан Республикасы порталы аша халыкның мәшгульлек үзәгенә туры килә торган эшнең ике вариантын сайлап алу турындагы мәгълүматны үз эченә алган, тәкъдим ителгән эшләрнең (вакансияләрнең) рангланган исемлеген туры килә торган эшләр (вакансияләр) исемлеген алган көннән соң ике эш көне эчендә җибәрү зарурилыгы турында.

Туры килә торган, тәкъдим ителгән эшләрнең (вакансияләрнең) чираттагы һәр исемлеге «Работа в России» порталына туры килә торган эшнең ике варианты буенча эшкә алучы белән сөйләшүләр уздыру көне һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат алынган көннән соң яисә эшкә алучының мөрәҗәгать итүченең килгән көне һәм эшкә алудан баш тарту сәбәбе турындагы тамгасы белән юллама мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылганнан соң бер эш көненнән соңга калмыйча җибәрелә.

Халыкның мәшгульлек үзәге туры килә торган, тәкъдим ителгән эшләр (вакансияләр) исемлеге белән бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы закон нигезләмәләре турында да мәгълүмат җиткерә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән туры килә торган эш вариантын сайлап алу.

3.5.5. Эш бирүче белән мөрәҗәгать итүче кандидатурасын килештерү

Халыкның мәшгульлек үзәге эш бирүчеләрдән эшкә урнашу турында килешү алганчы, мөрәҗәгать итүче тарафыннан төзелгән, туры килә торган, тәкъдим ителгән эшләр (вакансияләр) исемлеге нигезендә, эшкә алу турында гражданин белән сөйләшүләр уздыруга эшкә алучылардан риза булуга раслама

алганчыга кадәр, мөрәҗәгать итүче кандидатурасын эш бирүчеләр белән килештерә.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче тарафыннан төзелгән, туры килә торган, тәкъдим ителгән эшләрнең (вакансияләрнең) ике өстенлекле вариантыннан башлап һәм алга таба - мөрәҗәгать итүче билгеләгән өстенлеклелек тәртибендә актуальлеген тикшерә.

Туры килә торган, тәкъдим ителгән эшләрнең (вакансияләрнең) актуальлеген тикшерү нәтиҗәләре буенча халыкның мәшгульлек үзәге эш бирүчеләр белән туры килә торган эшнең ике варианты буенча сөйләшүләр үткәрүгә мөрәҗәгать итүченең кандидатурасын килештерә.

Килештерү, «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрен (алга таба – «Интернет» челтәре) дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларын кулланып гамәлгә ашырыла. Телефон элемтәсе чаралары буенча шалтыратулар эшкә алучының элемтә телефоны буенча көндезге вакытта эш бирүченең сәгать поясы буенча башкарыла.

Эш бирүчедән гражданин кандидатурасын сөйләшүләр үткәрү өчен раслау алган вакытта, халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталына тиешле мәгълүматны кертә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән туры килә торган, тәкъдим ителгән эшләр (вакансияләр) исемлеген алган көннән алып бер эш көненнән дә артмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче белән мөрәҗәгать итүчене әңгәмәгә җибәрүне килештерү яки «Интернет» челтәреннән файдаланып, телефон яки видеоэлемтә аша әңгәмә үткәрү.

3.5.6. Эшкә алучы белән сөйләшүләр уздырылуы турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү җибәрү һәм, эшкә алучы «Работа в России» порталында теркәлмәгән булса, туры килә торган эшнең ике варианты буенча мөрәҗәгать итүчегә эшкә юлламалар бирү

Хлыкның мәшгульлек үзәге, эш бирүче белән килештерү нәтиҗәләре нигезендә, гражданинга «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүчедән туры килә торган эш (вакансияләр) тәкъдимнәренең төзелгән исемлеген алган көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр уздырылуы турында белдерү җибәрә.

Эш бирүче «Работа в России» порталында теркәлмәгән булса, халыкның мәшгульлек үзәге 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык белән расланган форма буенча эшкә юллама рәсмиләштерә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән туры килә торган, тәкъдим ителгән эшләр (вакансияләр) исемлеген алган көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бер үк вакытта ике белдерү (эшкә юллама) рәсмиләштерү һәм җибәрү (бирү).

3.5.7. Эшсез дип танылуга дәгъва белдерүче мөрәҗәгать итүчегә, эшсез мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгеннән эшкә алучы белән сөйләшүләр уздырылуы турында белдерү яки, эшкә алучы «Работа в России»

порталында теркәлмәгән булса, эшкә юллама алынган көннән башлап өч эш көне эчендә «Работа в России» порталын, шул исәптән Бердәм порталны, Татарстан Республикасы порталын кулланып, электрон формада халыкның мәшгульлек үзәгенә туры килә торган эшнең ике варианты буенча эшкә алучы белән сөйләшүләр уздыру көне һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат тапшыру яки мөрәҗәгать итүченең килү көне һәм эшкә алудан баш тарту сәбәбе турында эшкә алучы тамгасы белән юллама тапшыру зарурлыгы турында хәбәр итү

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә:

халыкның мәшгульлек үзәгеннән белдерү (эшкә юллама) алынган көннән башлап өч эш көне эчендә «Работа в России» порталын кулланып, туры килә торган эшнең ике варианты буенча эш бирүчеләр белән вакансияләргә кайтаваз формалаштыру, эшкә урнашу турында сөйләшүләр алып бару датасын һәм вакытын эшкә алучы белән килештерү, «Работа в России» порталын кулланып, шул исәптәп Бердәм портал яисә Татарстан Республикасы порталы аша халыкның мәшгульлек үзәгенә туры килә торган эшнең сайланган ике варианты буенча эшкә алучы белән сөйләшүләр алып бару көне һәм нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны җибәрү һәм (яки), эшкә алучы «Работа в России» порталында теркәлмәгән очракта, эшкә алучының мөрәҗәгать итүченең килгән көне һәм эшкә алудан баш тарту сәбәбе турында тамгасы белән юлламаны тапшыру кирәклеге турында;

мөрәҗәгать итүче әлеге мәгълүматны халыкның мәшгульлек үзәгеннән белдерү (эшкә юллама) алганнан соң өч эш көне эчендә җибәрмәгән очракта һәм мөрәҗәгать итүче, вакытлыча рәвештәге эшне дә кертеп, туры килә торган эш эзләү максатларында теркәү исәбенә куелганнан соң 10 көн эчендә туры килә торган эшнең сайланган ике вариантыннан баш тарткан очракта, хокукый нәтиҗәләр турында.

Әлеге мәгълүмат эшкә урнашу турында сөйләшүләр үткәрү турындагы белдерүдә була.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре мөрәҗәгать итүчегә белдерүләр юллый:

а) «Работа в России» порталын кулланып гариза җибәргән очракта – «Работа в России» порталы аша. Гражданинга аңа белдерүләрне «Работа в России» порталы аша җибәрү турында хәбәр итү хәбәр текстларын автомат рәвештә формалаштыру һәм мөрәҗәгать итүченең гаризада күрсәтелгән электрон почтасына  җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла;

б) Бердәм порталны кулланып гариза җибәргән очракта – Бердәм портал аша;

в) гаризаны Татарстан Республикасы порталы аша җибәргән очракта – Татарстан Республикасы порталы аша.

Кирәк булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә «Мое собеседование» сервисын гамәлгә ашыру кысаларында эш бирүче белән сөйләшүләргә әзерлек узарга тәкъдим итә.

халыкның мәшгульлек үзәге халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән мөрәҗәгать итүчегә «Мое собеседование» сервисын гамәлгә ашыра.

Халыкның мәшгульлек үзәге «Мое собеседование» сервисын технологик карта нигезендә гамәлгә ашыра.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән көнне аңа технологик карта нигезендә эш бирүче белән сөйләшүләргә әзерлек, шул исәптән коммуникатив күнекмәләргә һәм үзпрезентация күнекмәләренә өйрәтү буенча һөнәри консультация бирә.

«Мое собеседование» сервисын гамәлгә ашырганда халыкның мәшгульлек үзәге сөйләшүләр уздыру өчен мөрәҗәгать итүче кандидатурасын килештергән эшкә алучы белән белән сөйләшүләргә әзерләнү һәм аларны үткәрү буенча мөрәҗәгать итүче өчен киңәшләр формалаштыра, шул исәптән мөрәҗәгать итүчене эшкә алучы турында гомуми билгеле булган мәгълүмат белән таныштыра, сөйләшүләрне уздыру вакытында эшкә алучы сорарга мөмкин булган документлар исемлеге турында хәбәр итә, сөйләшүләрне уздырганда мөәрәҗәгать итүчегә аның хезмәт хокуклары турында мәгълүмат бирә.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан оештырыла торган сөйләшүләрне үткәрүгә әзерлек буенча тренингларда катнашырга тәкъдим итә. Халыкның мәшгульлек үзәге сөйләшүләрне үткәрүгә әзерлек буенча тренингта катнашырга теләк белдергән очракта, мөрәҗәгать итүче белән аны үткәрү датасын һәм вакытын килештерә.

Тренинглар видео-конференц-элемтә ярдәмендә дә үткәрелергә мөмкин.

Турыдан-туры форматта тренинг үткәргән очракта, мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе халыкның мәшгульлек үзәгенә килеп, анда катнашу өчен тренинг үткәрүнең килешенгән көннәрендә килеп йөри.

Эшкә алучы Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законның 25 статьясының 5 пунктында каралган мәгълүматны тапшырмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге телефон буенча яки электрон элемтәне кулланып, шул исәптән «Интернет» челтәре аша, эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр алып бару нәтиҗәләрен тәгаенләштерү максатында эшкә алучы белән элемтәгә керә, шуннан соң әлеге мәгълүматны әлеге мәгълүмат эшкә алучы тарафыннан тапшырылган срок бетү белән киләсе эш көненнән соңга калмыйча, «Работа в России» порталына кертә.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчене эшкә урнаштыру турындагы мәгълүматларны ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып раслый.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүченең эшкә урнашуы турындагы мәгълүматларны «Работа в России» порталына ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып, әлеге мәгълүматларны раслаганнан соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча кертә.

Әңгәмә уздыру нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә эшкә урнаштырудан баш тартылган очракта, туры килә торган эшне эзләү түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

а) әлеге Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең булуын тикшерү;

б) халыкның мәшгульлек үзәге ярдәме белән мөрәҗәгать итүче белән үткәрелгән сөйләшүләрнең нәтиҗәләре белән танышу;

в) өстәмә алынган белешмәләрне һәм (яки) башка дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен исәпкә алып, туры килә торган эш эзләү критерийларын төгәлләштерү;

г) әлеге Регламентның 3.5.1 пунктында каралган административ процедураларны (гамәлләр) гамәлгә ашыру.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә әңгәмә узу вакыты һәм эш бирүче тамгасы белән эшкә бирелгән юлламаны тапшыру кирәклеге турында хәбәр итү.

3.5.8. Эшсез дип танылуга дәгъва итүче мөрәҗәгать итүченең туры килә торган эш вариантыннан баш тартуын рәсмиләштерү

Эшсез дип танылуга дәгъва итүче мөрәҗәгать итүче, эшсез гражданин туры килә торган эш вариантларыннан баш тарткан очракта яисә эшкә урнашу турында сөйләшүләр уздырудан баш тартканда һәм (яки) мөрәҗәгать итүче сайланган эш вариантлары буенча сөйләшүләр уздыру көне һәм нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрмәгән очракта яисә эшкә алучы мөрәҗәгать итүче килгән көн һәм эшкә алудан баш тарту сәбәбе турында тамгаланган юлламаны Регламентның 3.5.7 пунктында каралган срок эчендә халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырмаган очракта (эшкә алучы «Работа в России» порталында теркәлмәгән булса), әлеге факт «Работа в России» порталында теркәлә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең тәкъдим ителгән эш вариантларыннан баш тартуы.

3.5.9. Туры килә торган эш вариантлары булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим итә:

эш эзләү критерийларын төгәлләштерү максатында резюмега төзәтмәләр кертү (кирәк булганда), шул исәптән «Мое резюме» сервисын гамәлгә ашыру кысаларында да;

чиктәш һөнәр буенча эш (белгечлек);

хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар таләпләренә җавап бирә торган, эш бирүчеләргә мөстәкыйль рәвештә бару өчен, вакытлыча характердагы эшне дә кертеп, түләүле эш вариантлары;

эш урынына транспорт белән бару мөмкинлеген исәпкә алмаган, ләкин Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законда каралган башка критерийларга туры килә торган эш, бер үк вакытта эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка урынга күченгәндә эшсез гражданнарга һәм күченеп урнашканда эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тәкъдим итеп;

билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча

өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне;

башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне;

халыкны эш белән тәэмин итү турында законның 7.1-1 статьясында билгеләнгән халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләре күрсәтүне.

Халыкның мәшгульлек үзәге халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән мөрәҗәгать итүчегә «Мое резюме» сервисын гамәлгә ашыра.

Халыкның мәшгульлек үзәге Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан эшләнгән технологик карта (алга таба - технологик карта) нигезендә «Мое резюме» сервисын гамәлгә ашыра.

Мөрәҗәгать итүчегә резюме төзергә кирәк булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән көнне, резюме төзү буенча һөнәри консультация бирү максатыннан, мөрәҗәгать итүче турында, шул исәптән аның квалификациясе, эш стажы, белем дәрәҗәсе, теләгән эш хакы дәрәҗәсе, теләгән эшчәнлек өлкәсе, теләгән һөнәре (белгечлеге, вазыйфасы) турында мәгълүмат алу өчен, аның белән интервью үткәрә.

Мөрәҗәгать итүче белән интервью уздырылганнан соң, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә технологик картага туры китереп резюме төзү буенча һөнәри консультация бирә.

Мөрәҗәгать итүченең резюмесы булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән көнне, эш эзләү критерийларын ачыклау максатыннан, резюмены анализлый. Резюмега төзәтмәләр кертергә кирәк булганда, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә технологик картага туры китереп резюмены төзәтү буенча һөнәри консультация бирә.

Һөнәри консультация тәмамлангач, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә үз резюмесын мөстәкыйль рәвештә төзергә (төзәтмәләр кертергә) тәкъдим итә. Мөрәҗәгать итүченең ихтыяры буенча резюмены төзү (корректировкалау) аның тарафыннан турыдан-туры халыкның мәшгульлек үзәгендә булганда гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчене резюме төзү (корректировкалау) өчен компьютер белән җиһазландырылган урын белән тәэмин итә.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә резюмены төзеп бетергәннән соң шунда ук аны төзеп бетерү (төзәтмәләр кертү) буенча бәяләргә тәкъдим итә.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүченең ихтыяры буенча мөрәҗәгать итүче тарафыннан төзелгән (төзәтмә кертелгән) резюмега бәя бирә. Резюмены эшләп бетерү өчен нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге, конкуренциягә сәләтен арттыру максатларында, резюмены эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр формалаштыра.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә «Работа в России» порталына резюмены урнаштыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә барган көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәге киңәшләрен исәпкә алып төзелгән резюме.

«Работа в России» порталында чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча ирекле эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматлар булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләрне үз эченә алган исемлекне төзи һәм аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча эш вариантларын мөрәҗәгать итүче белән килештерү һәм мөрәҗәгать итүче кандидатурасын эш бирүче белән килештерү әлеге Регламентның 3.5.4 - 3.5.5 пунктларында каралган гамәлләр эзлеклелеге нигезендә гамәлгә ашырыла.

Чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык белән расланган форма буенча эшкә юлламаны рәсмиләштерү һәм риза булган очракта, аны мөрәҗәгать итүчегә бирү әлеге Регламентның 3.5.6 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече Физик затлар регистрында түләүле эшнең теләсә нинди вариантын сайлый, шул исәптән вакытлыча характердагы эшне дә кертеп, эш вариантлары исемлеген бастыра һәм эш бирүчеләргә мөстәкыйль рәвештә бару өчен мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим итә.

Мөрәҗәгать итүче халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим белән ризалашкан очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

вакантлы эш һәм уку өчен эш урыннары ярминкәсен үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Түләүле җәмәгать эшләрен уздыруны оештыру» халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру процессы стандартын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 931н номерлы боерыгы белән расланган түләүле җәмәгать эшләрен уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартында каралган административ гамәлләрне башкара;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән

25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеге стандартын раслау турында» 2022 елның 28 гыйнварындагы 25н номерлы боерыгы белән расланган 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) башкара;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне башкару процессы стандартын раслау турында» 2022 елның 25 февралендәге 81н номерлы боерыгы белән расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) башкара.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

мөрәҗәгать итүчегә чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама бирү һәм рәсмиләштерү; эш бирүчеләргә мөстәкыйль рәвештә бару өчен, мөрәҗәгать итүчегә буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне тәкъдим итү;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим;

халыкның мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем бирүне тәкъдим итү.

3.5.10. Халыкның мәшгульлек үзәге өч яшенә җиткәнче бала карау буенча отпускта булган хатын-кызларга, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген дәвам итәргә омтылган гражданнарга эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча профессиональ укырга яки өстәмә һөнәри белем алырга тәкъдим итә.

Туры килә торган эш булмаганда халыкның мәшгульлек үзәге белгече туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтен күрсәткәндә өч яшенә җиткәнче бала карау буенча отпускта булган хатын-кызга, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген дәвам итәргә омтылган гражданинга мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча профессиональ укырга яки өстәмә һөнәри белем алырга тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: өч яшькә җиткәнче бала карау ялында булган хатын-кызны, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт

эшчәнлеген яңартырга омтылган эшсез гражданин өчен мәшгульлек органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу яисә өстәмә һөнәри белем бирү вариантын сайлап алу.

3.5.11. Физик затлар регистрына административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен кертү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече физик затлар регистрында түбәндәгеләрне терки:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен (мөрәҗәгать итүчегә эшкә юллама, буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлек җибәрү (бирү), туры килә торган эш вариантыннан баш тарту);

халыкны эш белән тәэмин итүнең актив сәясәте чараларында катнашу өчен юллау факты (мөрәҗәгать итүчегә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим биргәндә, халыкның мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча, шул исәптән, өч яше тулганчы бала карау ялында булган чорда хатын-кызларга халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан һөнәри уку узарга тәкъдим итү).

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш эзләүдә дәүләт хезмәте күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен Физик затлар регистрында теркәү.»;

3.6 пунктта:

3.6.1, 3.6.2 пунктларда «әлеге Регламентның 2.5 пунктында» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.6 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

3.6.1, 3.6.5 пунктларда «әлеге Регламентның 3.5.1 пунктының 3-12 пунктчаларында» сүзләрен «әлеге Регламентның 3.5.1 пунктының 2-10 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

3.6.5 пунктында «әлеге Регламентның 3.5.4 – 3.5.13 пунктларында» сүзләрен «әлеге Регламентның 3.5.3 – 3.5.11 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары»;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына (белешмәлек) кушымта

# ГРАЖДАННАРГА ТУРЫ КИЛӘ ТОРГАН ЭШ ЭЗЛӘҮДӘ ЯРДӘМ ИТҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕ ТИКШЕРЕП ТОРУ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ОРГАННАР (ОЕШМАЛАР) ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР

## 1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре

| Халыкның мәшгульлек үзәге атамасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85592) 7-57-90 | Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84344) 2-80-52 | Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85552) 3-09-83 | Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84341) 2-48-31 | Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84346) 2-15-89 | Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(8553) 32-34-99 | Czn.Almet@tatar.ru |
| «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84376) 2-12-15 | Czn.Apastovo@tatar.ru |
| «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84366) 3-29-33 | Centr.Arskiy@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(884369) 2-34-24 | Czn.Atnya@tatar.ru |
| «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(885569) 5-27-10 | Czn.Bavly@tatar.ru |
| «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84368) 2-52-34 | Czn.Baltasi@tatar.ru |
| «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85594) 4-17-60 | Czn.Bugulma@tatar.ru |
| «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84374) 3-35-89 | Czn.Buinsk@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84379) 2-24-28 | Czn.V-uslon@tatar.ru |
| «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84365) 3-16-17 | CZN.VGora@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84375) 2-25-87 | Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85557) 7-58-58 | Czn.Elabugi@tatar.ru |
| «Зәй ш. халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85558) 7-15-43 | Czn.Zainsk@tatar.ru |
| «Зеленодольск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84371) 5-64-92 | Czn.Zdol@tatar.ru |
| «Кайбыч районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84370) 2-12-60 | Czn.Kaibicy@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84364) 2-67-54 | Czn.Kukmor@tatar.ru |
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84378) 2-48-12 | 35 йорт Laish.Czn@tatar.ru |
| «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85595) 5-58-81 | Czn.Leninogorsk@tatar.ru |
| «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85563) 3-35-57 | Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| «Менделеевсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85549) 2-02-02 | Czn.Men@tatar.ru |
| Әгерҗе районы буенча «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | 8(85551) 2-31-73 | Centr.Agryzskiy@tatar.ru |
| «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85555) 3-23-80 | Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85556) 2-48-34 | Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| «Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(8552) 52-42-68 | Chelny.CZn@tatar.ru |
| Тукай районы буенча «Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | 8(8552) 52-96-97 | Czn.Tukaev@tatar.ru |
| «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(8555) 42-40-79 | Czn.Nk@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ Кама Аланы бүлеге | 8(8555) 33-98-61 | kampol.czn@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84348) 2-23-43 | Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| «Нурлат шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84345) 2-46-30 | Czn.Nurlat@tatar.ru |
| «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84367) 3-06-06 | CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84361) 2-21-81 | Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84362) 2-28-15 | SZN.Saby@tatar.ru |
| «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85559) 2-42-62 | Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84347) 3-07-72 | Czn.Bolgar@tatar.ru |
| «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84373) 2-63-40 | Czn.Tetyushi@tatar.ru |
| Кама Тамагы районы буенча «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | 8(84377) 2-14-67 | Filial.K-uste@tatar.ru |
| «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84360) 2-13-51 | Czn.Tyulyachi@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84396) 2-54-59 | Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(84342) 5-13-34 | Czn.chist@tatar.ru |
| «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(85593) 2-60-16 | Czn.Yutazy@tatar.ru |
| «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(843) 562-48-33 | Czn.g_Kazan@tatar.ru |
| Совет районы буенча «Казан ш. халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | 8(843) 273-85-03 | CZN.Sovetskiy@tatar.ru |
| «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(843) 537-86-00 | Czn.Avia@tatar.ru |
| «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(843) 277-40-09 | Czn.Yah@tatar.ru |
| «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(843) 554-77-36 | czn.kirovskiy@tatar.ru |
| «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(843) 564-58-72 | czn.moskovski@tatar.ru |
| «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(843) 560-88-98 | Czn.Novosavin@tatar.ru |
| «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директоры | 8(843) 224-86-83 | CZN.Privol@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа атамасы | Телефон | Электрон адрес |
| --- | --- | --- |
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Хезмәт базарын анализлау һәм фаразлау, дәүләт хезмәтләре күрсәтү мониторингы бүлеге башлыгы | 557-20-93 | Irina.Posokova@tatar.ru». |